**МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИРҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

13.10.2015 № 545-пр

Казан ш.

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына алынган гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау тәртибен раслау турында**

«Татарстан Республикасы гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 12 май, 2003 ел, № 16-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 23 статьясындагы 3 өлеше нигезендә, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына алынган гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау тәртибен (алга таба – Тәртип) (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Министр урынбасарларына, идарәләр начальникларына хезмәткәрләрне Тәртип белән таныштыруны оештырырга һәм аның тайпылышсыз үтәлешен тәэмин итәргә.

3. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны эшләр идарәчесе А.Х.Камаловка йөкләргә.

**Министр вазыйфаларын башкаручы** **С.А.Демидов**

Татарстан Республикасы Җир
һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының 13.10.2015 ел,
№ 545-пр боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына алынган гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына алынган гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлауның бу Тәртибе (алга таба – Тәртип) гражданнар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү эше сыйфатын яхшырту, шулай ук гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү формаларын һәм ысулларын камилләштерү, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауның сыйфатын яхшырту максатыннан чыгып эшләнде.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына (алга таба – Министрлык) алынган гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлауның максаты булып Министрлыкка мөрәҗәгать иткән гражданнарның актуаль проблемаларын өйрәнү, гражданнар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү буенча структур подразделениеләр эшчәнлеге турында объектив мәгълүматлар алу өчен, шулай ук анализ нәтиҗәләре буенча Министрлык эшчәнлеге нәтиҗәсен арттыру буенча нигезле тәкъдимнәр эшләү тора.

3. Министрлыкта гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибе «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү

тәртибе турында» 2 май, 2006 ел, № 59-ФЗ Федераль закон, шулай ук «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 12 май, 2003 ел, № 16-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә җайга салына.

4. Гражданнар тәкъдимнәрен, гаризаларын һәм шикаятьләрен кабул итү һәм карап тикшерүне оештыру өчен Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры, министр урынбасарлары (алга таба – Министрлык җитәкчелеге, гражданнарны шәхсән кабул итү буенча вәкаләтле затлар) һәм структур подразделениеләр җитәкчеләре җавап бирә.

5. Министрлыкта гражданнарның язмача, электрон документ рәвешендә һәм телдән мөрәҗәгатьләре белән эшләү, шулай ук Министрлыкка алынган гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ үткәрү Министрлыкның Делопроизводство һәм контрольлек бүлегенә (алга таба – Делопроизводство бүлеге) йөкләнә.

6. Министрлыкка алынган гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау яртыеллык һәм еллык йомгаклар буенча хәл ителә.

7. Министрлыкка алынган гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ тиешле чорга гражданнардан алынган барлык мөрәҗәгатьләр буенча, шул исәптән язмача, электрон хәбәр рәвешендә эшләнгән, Интернет-кабул итү бүлеге аша җибәрелгән, Министрлыкның рәсми сайтына урнаштырылган мөрәҗәгатьләр буенча, шулай ук гражданнарны шәхсән кабул итү (Министрлык җитәкчелеге тарафыннан) барышында кабул ителгән мөрәҗәгатьләр буенча хәл ителә.

8. Тиешле чорда министрлыкка алынган гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ алдагы елның шушы ук чорында алынган гражданнар мөрәҗәгатьләре белән чагыштыру нигезендә хәл ителә.

9. Министрлыкка алынган гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясалганда алынган мөрәҗәгатьләрнең саны (мөрәҗәгатьләрнең төрләре, авторларның тибы, физик затлар яки аноним мөрәҗәгатьләр буенча), тиешле чордагы гражданнар мөрәҗәгатьләрендә бәян ителгән мәсьәләләр тематикасы исәпкә алына, мөрәҗәгатьләрдә күтәрелгән мәсьләләрнең төп тематикасы билгеләнә, шулай ук гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүнең нәтиҗәсен арттыруга һәм Министрлыкта аларны үтәү срокларына контрольлек итүгә ярдәм итәрдәй чаралар исемлеге булдырыла.

10. Министрлыкның структур подразделениеләре, гражданнарны шәхсән кабул итүне оештыруга җаваплы затлар ярты еллыкның һәм елның соңгы аеннан соң килүче айның 5 нче числосыннан да соңга калмыйча, алынган, башка адреска җибәрелгән һәм карап тикшерелгән язмача мөрәҗәгатьләрнең саны, электрон документ рәвешендәге мөрәҗәгатьләрнең саны, шәхсән кабул итү барышында кабул ителгән гражданнар саны, мөрәҗәгатьләр тематикасы, мөрәҗәгатьләрне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча күрелгән чаралар турында мәгълүматлардан, шул исәптән кабул ителгән норматив-хокукый һәм башка актлар (булганда) турында мәгълүматлардан торган белешмәләрне әзерләп, Делопроизводство бүлегенә тапшыра.

11. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү тәртибе Министрлыкта Делопроизводство буенча инструкция нигезендә хәл ителә.

12. Делопроизводство бүлеге, бу Тәртипнең 10 пункты нигезендә, структур подразделениеләр тарафыннан тапшырылган мәгълүматлар буенча ярты еллыкның һәм елның соңгы аеннан соң килүче айның 10 нчы числосыннан да соңга калмыйча, тиешле чорда Министрлыкта гражданнар

мөрәҗәгатьләре белән эшләү турында аналитик белешмә (алга таба – аналитик белешмә) тутыра.

13. Аналитик белешмә түбәндәге мәгълүматларны үз эченә ала:

кабул итеп алынган, башка адреска җибәрелгән һәм карап тикшерелгән язмача мөрәҗәгатьләр саны турында, электрон документлар рәвешендә кабул итеп алынган мөрәҗәгатьләр саны, гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре турында, шәхсән кабул итү вакытында кабул ителгән гражданнар саны турында, гражданнарны шәхсән кабул итү һәм шәхсән күчмә кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында, мөрәҗәгатьләр тематикасы турында, мөрәҗәгатьләрне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив-хокукый актлар һәм башка актлар (булганда) турында мәгълүматлар;

алдагы елның шушы ук чоры белән чагыштырганда гражданнар мөрәҗәгатьләренең гомуми саны арту яки кимүе турында нәтиҗәләр;

хисап чорында һәм алдагы елның шушы ук чорында Татарстан Республикасы югары башкарма хакимият органнарыннан алынган гражданнар мөрәҗәгатьләре санын аныклау;

гражданнар мөрәҗәгатьләрендә бәян ителгән, Министрлык компетенциясе нигезендә иң еш бирелә торган сораулар турында йомгак.

14. Алынган гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ Делопроизводство бүлеге тарафыннан Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына (http: // mzio.tatarstan.ru) ярты еллыкның һәм елның соңгы аеннан соң килүче айның 15 нче числосыннан да соңга калмыйча урнаштырыла.